СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.08.2021 Әгерҗе шәһәре № 11-10

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында гражданнар милкенә җир кишәрлекләрен түләүсез тапшыруның уртача район нормасы турында

"Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында" 2002 елның 24 июлендәге 101-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Җир кодексының 40 статьясындагы 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Әгерҗе муниципаль районында 5,93 га күләмендә авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына билгеләнгән гражданнар милкенә җир кишәрлекләрен түләүсез тапшыруның уртача район нормасын билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, «Татмедиа» АҖ филиалының «Әгерҗе хәбәрләре» газетасында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре, экология, табигый ресурслар һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе А.Р.Вәлиев